РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» декабрь 2023ел Олы Кайбыч ав. №234

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2022 елның 24 маендагы 122 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составына Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлекчәсе башлыгы Вахитов Айрат Рөстәм улын комиссия әгъзасы итеп кертергә (килешү буенча);

комиссия составыннан Шакиров Альберт Әсхәт улын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин